| ИНСПЕКЦИЯ ГОСУДАРСТВЕННОГО СТРОИТЕЛЬНОГО НАДЗОРА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ДӘҮЛӘТ ТӨЗЕЛЕШ КҮЗӘТЧЕЛЕГЕ ИНСПЕКЦИЯСЕ |
| --- | --- | --- |

| ПРИКАЗ | | БОЕРЫК |
| --- | --- | --- |
| 11 декабрь, 2014 | Казан шәһәре | № 116 |

Татарстан Республикасы Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясендә вазыйфа биләү коррупция куркынычларына бәйле булган Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары исемлеген раслау турында

«Коррупциягә каршы көрәш турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы федераль закон, «Коррупциягә каршы көрәш турында» федераль законның аерым нигезләмәләрен гамәлгә ашыру чаралары турында» 2010 елның 30 сентябрендәге ПУ-636 номерлы Татарстан Республикасы Президенты указы нигезендә,

БОЕРЫК БИРӘМ:

1. Татарстан Республикасы Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясендә вазыйфа биләү коррупция куркынычларына бәйле булган Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары исемлеген (алга таба – Исемлек) расларга (кушымтада бирелә), алар буенча вазыйфаи бурычларны үтәү түбәндәгеләрне күздә тота:

хакимият вәкиле функцияләрен яисә оештыру-боеру яисә административ-хуҗалык функцияләрен даими рәвештә, вакытлыча яки махсус вәкаләтләр нигезендә гамәлгә ашыру;

гражданнарга һәм оешмаларга дәүләт хезмәтләре күрсәтү;

бюджет ассигнованиеләрен, субсидияләрне, бюджетара трансфертларны бүлү турында карарлар әзерләү һәм кабул итү, шулай ук чикләнгән ресурсны бүлү;

дәүләт мөлкәте белән идарә итү;

дәүләт сатып алуларын гамәлгә ашыру;

матди-техник ресурсларны саклау һәм бүлү.

2. Юридик бүлек башлыгына (Курневич Н.А.) әлеге боерыкны дәүләт теркәвенә алу өчен Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына җибәрергә.

3. Мәгълүмат-техник бүлегенә (Вишнякова С.Г.) әлеге боерыкны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Хөкүмәте рәсми порталының Татарстан Республикасы Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясе сайтында «Коррупциягә каршы тору» бүлегендә урнаштырырга.

4. Дәүләт хезмәте һәм кадрлар сәясәте мәсьәләләре бүлегенә (Мөхәммәтҗанова Г.И.) әлеге боерыкны Исемлеккә кертелгән Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларын биләүче Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренә җиткерергә.

5. Әлеге Боерык үтәлешен контрольдә тоту буенча үземне җаваплы итеп билгелим.

Җитәкчесе В.А. Кудряшов

Татарстан Республикасы
Дәүләт төзелеш күзәтчелеге
инспекциясенең 2014 елның 11
декабрендәге 116 номерлы
боерыгына кушымта

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ ТӨЗЕЛЕШ КҮЗӘТЧЕЛЕГЕ ИНСПЕКЦИЯСЕНДӘ ВАЗЫЙФА БИЛӘҮ КОРРУПЦИЯ КУРКЫНЫЧЛАРЫНА БӘЙЛЕ БУЛГАН ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ ГРАЖДАН ХЕЗМӘТЕ ВАЗЫЙФАЛАРЫ ИСЕМЛЕГЕ**

1. Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең иң югары вазыйфалар төркемендәге «җитәкчеләр» категориясе вазыйфасы:

Инспекция җитәкчесе.

2. Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең төп вазыйфалар төркемендәге «җитәкчеләр» категориясе вазыйфалары:

Инспекция җитәкчесенең беренче урынбасары,

Инспекция җитәкчесе урынбасары,

территориаль орган җитәкчесе.

3. Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең әйдәп баручы вазыйфалар төркемендәге «җитәкчеләр» категориясе вазыйфалары:

Инспекция аппараты бүлеге җитәкчесе,

Инспекция аппараты җитәкчесе урынбасары,

Инспекциянең территориаль органы җитәкчесе урынбасары,

Инспекциянең территориаль органы бүлеге җитәкчесе.

4. Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең әйдәп баручы вазыйфалар төркемендәге «белгечләр» категориясе вазыйфалары:

әйдәп баручы киңәшче,

әйдәп баручы консультант,

консультант.

5. Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең өлкән вазыйфалар төркемендәге «белгечләр» категориясе вазыйфалары:

әйдәп баручы белгеч-эксперт.

6. Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең әйдәп баручы вазыйфалар төркемендәге «тәэмин итүче белгечләр» категориясе вазыйфалары:

әйдәп баручы белгеч,

1 разрядлы өлкән белгеч.

7. Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең өлкән вазыйфалар төркемендәге «тәэмин итүче белгечләр» категориясе вазыйфалары:

2 разрядлы өлкән белгеч,

3 разрядлы өлкән белгеч.